РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КОРСАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422051, Республика Татарстан, Сабинский район, с.Корсабаш, ул. Дорожная, 1
тел. (84362) 49-7-26

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КУРСАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422051, Татарстан Республикасы, Саба районы, Курсабаш авылы, Юл урамы, 1 йорт
тел. (84362) 49-7-26

e-mail: korsab.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

30.04.2018 г. — № 18

"Муниципаль милек булып торучы җирләрне торак төзелеше максатында комплекслы үзләштерү өчен җир биләмәләрен арендалауга килешү хокукын төзү һәм сату буенча аукцион оештыру һәм үткәрү" муниципаль хезмәте күрсәтү буенча Административ регламент раслау турында

Россия Федерациясе Җир Кодексы, Россия Федерациясе Гражданлык Кодексы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның төп принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ; «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 27.07.2010 №210-ФЗ; Курсабаш авыл җирлеге Советы Уставы; Курсабаш авыл җирлеге Советының “Муниципаль районның җирле әһәмияттәге аерым сорауларны чишү буенча вәкаләтләренең бер өлешен бирү турында” 26.02.2015 №12 карары; Саба муниципаль районы башкарма комитеты белән Курсабаш авыл җирлеге башкарма комитеты арасында җирле әһәмияттәге аерым сорауларны чишү буенча 26.02.2015 елда төзелгән килешүгә туры китереп, Курсабаш авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. "Муниципаль милек булып торучы җирләрне торак төзелеше максатында комплекслы үзләштерү өчен җир биләмәләрен арендалауга килешү хокукын төзү һәм сату буенча аукцион оештыру һәм үткәрү" муниципаль хезмәте күрсәтү Административ регламентын расларга.(теркәлә)

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/korsabash адресы буенча урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешен тикшерүне үз өстемә алам.

Курсабаш авыл җирлеге башлыгы — А.Р. Гыймадиев

30.04.2018 елгы №18 карарына

кушымта №1

"Муниципаль милек булып торучы җирләрне торак төзелеше максатында комплекслы үзләштерү өчен җир биләмәләрен арендалауга килешү хокукын төзү һәм сату буенча аукцион оештыру һәм үткәрү" муниципаль хезмәте күрсәтү буенча Административ регламент

## I. Гомуми нигезләмәләр.

1. 1."Муниципаль милек булып торучы җирләрне торак төзелеше максатында комплекслы үзләштерү өчен җир биләмәләрен арендалауга килешү хокукын төзү һәм сату буенча аукцион оештыру һәм үткәрү" муниципаль хезмәте күрсәтү буенча Административ регламент (алга таба – муниципаль хезмәт) муниципаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәләрен аңлаешлы итү һәм үтәлеш сыйфатын арттыру, гариза бирүчегә уңайлы шартлар тудыру, муниципаль хезмәт күрсәтү стандартларын урнаштыру, административ процедураларны үтәү сроклары һәм тәртипләренә таләпләрне яхшырту максатында эшләнгән.

1.2. Муниципаль хезмәт үз эченә җир кишәрлегенә хокукны аукцион үткәрү юлы белән алу мәсьәләсен чишү һәм хәл итүне ала.

1.3. Муниципаль хезмәтне алучылар булып физик яки юридик затлар, яисә Россия Федерациясе закончалыкларына нигезләнеп, муниципаль хезмәт күрсәткәндә вәкаләтле орган белән үзара хезмәттәшлектә алар исеменнән эшләргә вәкаләтле затлар тора.

1.4. Муниципаль хезмәт ТР Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә.(алга таба –МБ идарәсе)

Муниципаль хезмәт күрсәтү урыны: ТР Саба районы, Курсабаш авылы, Юл ур., 1.
Телефон: 8(843) 62-49-726 E-mail: Korsab.Sab@tatar.ru Официаль сайт адресы: http://saby.tatarstan.ru/korsabash.
МБ идарәсе түбәндәге график буенча эшли: кабул итү көннәре: дүшәмбе, сишәмбе,чәршәмбе 7.00-11.00, 13.00-16.00, якшәмбе – ял көне.

1.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында консультацияләр(белешмәләр) МБ идарәсенең аукционда катнашуга гаризалар кабул итү вазыйфасы йөкләнгән җаваплы башкаручылары тарафыннан бирелә.
1.6. Шәхси киңәш бирүләр телдән һәм язмача башкарыла.
1.7. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча телдән шәхси киңәш бирүләр МБ идарәсенең җаваплы башкаручылары тарафыннан
-шәхси мөрәҗәгать буенча;
-язмача мөрәҗәгать буенча;
-телефоннан;

-электрон почта аша башкарыла.
1.8. Консультацияләр түбәндәге сораулар буенча бирелә:
- муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге;
- гаризага теркәлүче документларга таләпләр;
- документларны кабул итү һәм бирү вакыты;
- муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары;
- муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителүче карарларны һәм гамәлләрне шикаять итү тәртибе.
1.9. Шәхси язмача консультацияләү кызыксынучы затның МБ идарәсенә язмача мөрәҗәгате нигезендә башкарыла. Язмача җавап, муниципаль берәмлек башлыгының имзасы белән, мөрәҗәгать кергән берәмлек башкаручысының фамилиясе, инициаллары һәм телефон номеры күрсәтелеп бирелә. Җавап, мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгате ысулына яки тапшыру юлына карап, сорау кергәннән соң 30 көн эчендә хат, электрон почта яки факс белән җибәрелә.

Гариза кабул ителгәннән соң, әлеге административ регламентның 1.4 пунктында күрсәтелгәнчә, гариза бирүче телефоннан, электрон почта аша яисә шәхси кабул итү тәртибендә муниципаль хезмәтнең үтәлү барышы белән танышып барырга хокуклы.
1.10. Телефон шылтыратуларына, МБ идарәсенең җаваплы башкаручылары, мөрәҗәгать итүчеләрне кызыксындырган сорауларга итагатьле итеп һәм тулы җавап бирәләр. Телефон шылтыратуына җавап оешманың исемен, җавап бирүче белгечнең фамилиясе, исеме, атасының исемен, вазыйфасын әйтүдән башланырга тиеш.
1.11. Телефоннан консультация бирү вакыты – 5 минут.
1.12. Телефон шылтыратуын кабул иткән җаваплы башкаручының бирелгән сорауга җавап бирә алмау очрагында, шылтыратуны башка җаваплы башкаручыга күчерергә яисә мәгълүмат алырга мөмкин булган башка телефон номеры әйтелергә тиеш.
1.13. Сөйләшү вакытында җаваплы башкаручы сүзләрне аермачык әйтергә, башкалар белән сөйләшмәскә тиеш. Башка телефон аппаратына шылтырау килү сәбәпле, сөйләшүне туктатып тору катгый тыела.
1.14. Бер үк вакытта телефоннан белешмә бирү һәм документлар кабул итү тыела.
1.15. Ачыктан- ачык язмача мәгълүмат бирү, материалларны вакытлы матбугатта, мәгълүмати стендларда, шулай ук МБ идарәсенең рәсми сайтларында урнаштыру юлы белән башкарыла.

## II. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартлары.

2.1. Муниципаль хезмәтнең исеме: "Муниципаль милек булып торучы җирләрне торак төзелеше максатында комплекслы үзләштерү өчен җир биләмәләрен арендалауга килешү хокукын төзү һәм сату буенча аукцион оештыру һәм үткәрү".
2.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның исеме – МБ идарәсе.
2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсе булып аукционда җиңүче белән җир кишәрлеген сату-алу килешүе һәм аренда килешүе төзү тора.
2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары: аукцион үткәрү турында вакытлы матбугатта хәбәр чыкканнан алып аукционда җиңүче белән җир кишәрлеген сату-алу һәм арендалау килешүе төзегәнгә кадәр. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы 2 айдан артмаска тиеш.
2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтүгә хокукый нигезләр булып:
- Россия Федерациясенең Гражданлык Кодексы;

- Россия Федерациясенең Җир Кодексы;
- "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның төп принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль Законы;
- «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 27.07.2010 №210-ФЗ Федераль Законы;
- "Курсабаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең Уставы;
- Россия Федерациясенең башка норматив-хокукый актлары һәм законнары, МБ идарәсенең муниципаль хокукый актлары тора.

2.6. Муниципаль хезмәтне алу өчен, муниципаль милек булып торучы җирләрне торак төзелеше максатында комплекслы үзләштерү өчен җир биләмәләрен арендалауга килешү хокукын төзү һәм сату буенча аукционда катнашырга теләүчеләр, МБ идарәсенә түбәндәге документларны китерә:
- аукционда катнашу өчен, аукцион үткәрү турында хәбәрдә күрсәтелгән формада, алдан бирелгән акчаны кайтару өчен банк реквизитлары белән счет күрсәтелгән сорау язуы;
- гариза бирүченең шәхесен раслаучы документлар күчермәсе (гражданнар өчен);
- гариза бирүче булып чит ил юридик заты торган очракта, юридик затның дәүләт теркәве узуы турында документларының тиешле таләпләргә туры китереп расланган рус теленә тәрҗемәсе;
- алдан бирелгән акчаны раслаучы документлар.

2.7. Алдан бирелгән акчаны раслаучы документлар, алдан акча бирү килешүе белән раслана.

2.8. МБ идарәсе әлеге регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документлардан башка документлар таләп итәргә тиеш түгел. Гариза бирүче юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләргә карата МБ идарәсе, юридик затлар һәм физик затларны шәхси эшмәкәр яки крестьян фермер хуҗалыгы буларак дәүләт теркәве уздыручы башкарма хакимиятнең федераль органыннан, юридик затларның бердәм дәүләт реестрында яки шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрында булу фактын раслаучы белешмәләрне соратып ала.

2.9. МБ идарәсе, аукционда катнашу өчен гариза кабул итү срогы узганнан соң бирелгән гаризаларны гариза бирүчегә көнендә кайтара.

2.10. МБ идарәсе җир биләмәләрен үзмилеккә сату буенча аукцион оештыру яки җир кишәрлеген арендалау килешүе төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүдән түбәндәге очракларда баш тарта:
- катнашу өчен кирәкле документларны тапшырмаган яки дөрес булмаган белешмәләр биргән очракта;
- аукционда катнашу өчен гаризаларны карау көненә алдан түләү кермәгән очракта;
- аукционда катнашу өчен гаризаны РФ законнчалыгы нигезендә билгеле аукционда катнашу, җир кишәрлеген сатып алу яки арендага алу хокукы булмаган зат биргән очракта;
- гариза бирүче, юридик зат булып торучы гариза бирүченең коллегиаль башкаручы органнары членнары, оештыручылары, гариза бирүченең аерым башкарма органы функцияләрен башкаручы затлар турында намуссыз аукционда катнашучылар реестрында мәгълүматлар булган очракта.

2.11. Муниципаль хезмәт бушлай күрсәтелә.

2.12. Аукционда катнашу өчен гариза биргәндә чират көтүнең максималь срогы 15 минуттан артмаска тиеш. Аукционда катнашу өчен гариза бирү һәм кабул итүнең гомуми вакыты 20 минуттан артмаска тиеш. Сату-алу килешүе яки аукцион җиңүчесе белән аренда килешүе төзегәндә чират көтү вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

2.13. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле биналарга, көтеп утыру урынына, гаризалар тутыру урынына, документлар исемлеге һәм тутыру тәртибе аңлатылган үрнәкләр күрсәтелгән мәгълүматлар стенды куелган урыннарга таләпләр:
- көтеп утыру залында утырып торырга урыннар һәм гариза тутыру өчен өстәл булырга тиеш;
- көтеп утыру залындагы стенада аукционда катнашу өчен гариза тутырганда кирәкле документлар исемлеге һәм гариза үрнәкләре куелган мәгълүмат стенды булырга тиеш;
- аукцион үткәрелә торган бина иркен, якты булырга, бөтен катнашучыларны сыйдырырлык утыргычлары булырга тиеш.

2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфаты һәм мөмкинлеге күрсәткечләре:
- муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап, гариза белән мөрәҗәгать итү тәртибе;
- МБ идарәсе эшчәнлегенең ачыклыгы;
- муниципаль хезмәт күрсәтүгә мөрәҗәгатьнең мөмкин булуы;
- муниципаль хезмәт күрсәтү срокларының үтәлеше;
- муниципаль хезмәт күрсәтү турында тулы, төгәл һәм актуаль белешмә алу.

## III. Административ процедураларның составы, үтәлү срогы һәм эзлеклелеге. Аларны үтәүгә таләпләр.

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:
- аукцион уздыру турында белдерүне МБ идарәсенең Интернет челтәрендәге рәсми сайтында (http://saby.tatarstan.ru/rus/zakaz.htm), шулай ук РФ-нең аукцион уздыру турында мәгълүматлар бастыру өчен официаль сайтында урнаштыру;
- аукционда катнашырга теләүчеләргә кирәкле мәгълүматны һәм документларны бирү;
- аукционда катнашырга теләк белдерүчеләрдән гаризаларны һәм аларга теркәлгән документларны кабул итү һәм теркәү;
- аукционда катнашырга теләк белдерүчеләрне тану яки гамәлдәге закончалыкларга нигезләнеп аларга аукционда катнашуга рөхсәт бирмәү турында карар кабул итү;
- аукционда катнашучы булып танылган дәгъвачыларга һәм аукционга кертелмәгән дәгъвачыларга язма хәбәр җибәрү;
- муниципаль милектәге җир кишәрлеген торак төзелеше максатында комплекслы үзләштерү өчен, аукцион шартларына туры китереп аукцион уздыру турында язма хәбәрдә күрсәтелгән барлык таләпләргә туры килгән сату-алу килешүе проектын яки аренда килешүе проектын аукционның бердән-бер катнашучысына, бердән-бер гариза бирүчесенә җибәрү;
- аукцион уздыру, аукцион нәтиҗәләре турында беркетмәне аукционда җиңүчегә тапшыру;
- сату-алу, аренда килешүен әзерләү һәм аукцион җиңүчесе белән килешү төзү;
- аукционда катнашу өчен алдан бирелгән акчаны кайтару (җиңүчедән башкаларга);
- аукционда катнашу өчен бирелгән гаризаларны карау беркетмәсен һәм аукцион нәтиҗәләре беркетмәсен Интернет челтәрендә рәсми сайтта бастыру.

3.2. Муниципаль хезмәт күрсәтә башлауга нигез булып администрациянең аукцион уздыру турында карары тора.

3.3. Аукцион уздыру турында язма хәбәр МБ идарәсенең Интернет челтәрендәге рәсми сайтында (http://saby.tatarstan.ru/rus/zakaz.htm), шулай ук РФ рәсми сайтында МБ идарәсе

тарафыннан аукцион уздыру көненнән 30 көннән дә соңга калмыйча урнаштырылырга тиеш.

3.4. МБ идарәсе, аукционда катнашырга теләк белдергән затларга, аукцион уздыру турында хәбәр рәсми басылган көннән алып, гариза бирүнең язма хәбәрдә күрсәтелгән соңгы көненә кадәр, телдән яки язмача формада, теләсә кайсы эш көнендә, белешмәләр, гариза бланклары, документлар күчермәләре бирә.

3.5. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торак төзелеше максатында комплекслы үзләштерү өчен, сату-алу килешүе яки аренда килешүе буенча аукционда катнашу өчен гаризалар кабул итү вакыты 25 көннән дә ким була алмый. Документлар кабул итү аукцион уздыру көненә 5 көн кала туктатыла.

Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торак төзелеше максатында комплекслы үзләштерү өчен сату буенча аукционда катнашырга теләүчеләр, әлеге административ регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән тәртиптә документлар теркәп, МБ идарәсенә гариза тапшыра.

МБ идарәсенең гаризалар кабул итүгә җаваплы белгече:

- Гаризалар һәм башка документлар аңлаешлы итеп язылган, юридик һәм физик затларның исемнәре кыскартуларсыз, банк реквизитлары , аларның урнашкан урыннары күрсәтелгән, гаризага кул куючының имзасы ачыкланган булуына;
- Документларда төрле төзәтүләр, бозулар булмавына;
- Документлар карандаш белән тутырылмавына;
- Документларда эчтәлеген төрле мәгънәдә аңлау мөмкинлеге булган мөһим ялгышлар булмавына инана.

МБ идарәсенең гаризалар кабул итүгә җаваплы белгече, тәртип номерын, сатылу объекты атамасын, катнашучының атамасын, гариза биргән көн һәм вакытны күрсәтеп, гаризалар кабул итү турындагы журналга терки, шулай ук документларның һәр нөсхәсенә документның номерын, бирелү көнен, вакытын, үзенең исем, фамилиясен күрсәтеп кул куя.

МБ идарәсенең гаризалар кабул итүгә җаваплы белгече гариза бирүче юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләргә карата юридик затлар һәм физик затларны шәхси эшмәкәр яки крестьян фермер хуҗалыгы буларак дәүләт теркәве уздыручы башкарма хакимиятнең федераль органыннан, юридик затларның бердәм дәүләт реестрында яки шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрында булу фактын раслаучы белешмәләрне соратып ала.

3.6. Язма хәбәрдә күрсәтелгән аукционда катнашучыларны билгеләү көнендә МБ идарәсе дәгъвачыларның гаризаларын һәм документларын карый, алардан билгеле счетларның күчермәләре нигезендә алдан түләү керүен барлый. Документларны караганнан соң МБ идарәсе, әлеге регламентның 2.10 пункты нигезендә, дәгъвачыларны аукционда катнаштыру яки катнаштырмау буенча карар кабул итә. Әлеге карар беркетмә белән рәсмиләштерелә, беркетмәдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

- аукционда катнашырга рөхсәт ителгән һәм танылган гариза бирүче, гариза бирү вакыты, алдан кертелгән түләүләр турында белешмә;
- аукционда катнашырга рөхсәт бирелмәгән гариза бирүчеләр турында катнаштырмау сәбәбен күрсәтеп, белешмә;

Аукционда катнашу өчен гаризаларны карау беркетмәсе, аларны караганнан соң бер көннән дә соңга калмыйча имзалана һәм имзаланганнан соң икенче көннән дә соңга калмыйча рәсми сайтта урнаштырыла.

3.7. Аукцион узмаган дип танылган яки бер гариза бирүче генә катнашучы дип танылган очракта, МБ идарәсе әлеге регламентның 3.6 пунктында күрсәтелгәнчә,

беркетмә имзаланганнан соң 10 көн эчендә, җир кишәрлеген сату-алу яки арендалау килешүенең имзаланган проектын 3 экземплярда гариза бирүчегә җибәрә.

3.8. Аукцион язма хәбәрдә күрсәтелгән урында, көндә һәм сәгатьтә уздырыла.

Аукцион узар алдыннан барлык катнашучылар теркәлергә тиеш. Катнашучыларның шәхесен раслаучы документы, килешү төзү өчен ышанычнамә(юридик затларны тәкъдим итүче физик затлар һәм башка физик затлар өчен) булырга тиеш. Катнашучыларны теркәү МБ идарәсе бинасында аукцион башланыр алдыннан уздырыла.

3.9.1. Бәяләр яки аренда түләве күләме турында тәкъдимнәр кертү буенча ачык аукцион түбәндәге тәртиптә уздырыла:

- теркәү вакытында аукционда катнашучылар, аукцион уздыручы җир кишәрлегенең башлангыч бәясен яки аренда түләвенең башлангыч күләмен һәм чираттагы бәяне яки аренда түләве күләмен әйткән саен күтәрү өчен, номерлы аукцион билетлары алалар;

- аукцион аукцион уздыручы тарафыннан җир кишәрлегенең атамасын, төп характеристикаларын, башлангыч бәясен яки аренда түләвенең башлангыч күләмен, “аукцион адымнарын” һәм үткәрү тәртибен хәбәр итүдән башлана. Аукцион барышында аукцион уздыручы башлангыч бәяне яки аренда түләвенең башлангыч күләмен хәбәр иткәннән соң, катнашучылар, номер күтәреп, әйтелгән бәя яки аренда түләве күләменә туры килгән җир кишәрлеген сатып алырга яки аренда килешүе төзергә әзер булуларын хәбәр итәләр;

- аукцион уздыручы алдагы бәяне яки аренда түләве күләмен «аукцион адымында» арттыра бара. Чираттагы бәяне яки аренда түләве күләмен әйткәннән соң, аукцион уздыручы беренче булып билет күтәрүченең номерын атый һәм шул катнашучыга төртеп күрсәтә. Аннары аукцион уздыручы чираттагы бәяне хәбәр итә;

- аукцион уздыручы тарафыннан чираттагы бәя 3 тапкыр хәбәр ителгәннән соң һәм чүкечнең соңгы тапкыр сугуына кадәр катнашучыларның берсе дә билетын күтәрмәсә аукцион тәмамлана. Аукцион уздыручы тарафыннан билет номеры соңгы булып әйтелгән катнашучы җиңүче дип таныла;

- аукцион тәмамланганнан соң аукцион уздыручы җир кишәрлегенең сатылуы яки аренда килешүе төзү хокукы алынуы турында хәбәр итә, сатылган яки арендага бирелгән җирнең бәясен һәм җиңүченең исемен атый.

Аукцион нәтиҗәләре беркетмә белән рәсмиләштерелә, беркетмә аукционны оештыручы, уздыручы һәм җиңүче тарафыннан аукцион узган көнне имзалана. Беркетмә 2 нөсхәдә төзелә, аның берсе аукцион җиңүчесенә бирелә, берсе оештыручыда кала.

Аукцион җиңүчесенә беркетмә МБ идарәсе тарафыннан аукцион уздырылган урында һәм көндә тапшырыла.

3.10. Аукционда бер генә катнашучы булган яисә катнашучыларның берсе дә аукцион барышында катнашмаган, яки башлангыч бәяне 3 тапкыр хәбәр иткәннән соң аны югарырак бәягә күтәрү турында тәкъдим булмаган очракта аукцион узмаган дип санала.

3.11. Аукцион нәтиҗәләре турында беркетмә аукционда җиңүче белән җир кишәрлеген сату-алу яки аренда иклешүе төзү өчен нигез булып тора.

Аукцион нәтиҗәләре турында беркетмә әлеге беркетмәне имзалаганнан соң бер эш көне эчендә рәсми сайтта урнаштырыла. МБ идарәсенең җир кишәрлеген сату-алу яки арендалау килешүен әзерләүгә җаваплы белгече, аукцион нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелгәннән соң 10(ун) көн эчендә, сату-алу яки җир кишәрлеген арендалау килешүенең имзаланган проектын 3(өч) нөсхәдә, аукционда җиңүчегә яки бердән-бер катнашучыга җибәрә.

Аукцион нәтиҗәләре турында белешмә рәсми сайтта урнаштырылганнан соң 10(ун) көн узмыйча, килешүләр төзү рөхсәт ителми.

3.12. Аукционда җиңүче яки әлеге регламентның 3.9, 3.10 пунктларына нигезләнеп, җир кишәрлеген сату-алу яисә арендалау килешүе төзелгән башка зат тарафыннан кертелгән алдан түләү акчасы, сатып алына торган җир өчен түләүгә яки аренда түләвенә күчерелә. Әлеге затлар тарафыннан кертелгән алдан түләүләр, килешү төзүдән баш тарту нәтиҗәсендә, билгеләнгән тәртиптә сату-алу яки җир кишәрлеген арендалау килешүен төземәгән очракта кире кайтарылмый. Аукционда катнашырга гариза биргән һәм катнашкан затларга(җиңүчеләрдән башка) аукционда катнашу өчен кертелгән алдан түләүләрне кире кайтару МБ идарәсенең вәкаләтле белгече тарафыннан, гариза бирүчеләрнең гаризаларында күрсәтелгән исәп-хисап счетына күчерү юлы белән түбәндәге срокларда кире кайтарыла:

- аукционга кертелмәгән затларга – җир кишәрлеген үзмилеккә сату яки аренда килешүе төзүгә хокукны сату буенча аукционда катнашырга гаризалар кабул итү буенча беркетмә төзелгәннән соң 3(өч) эш көне эчендә;

- аукционда катнашу өчен гаризаларын кире алган затларга - җир кишәрлеген үзмилеккә сату яки аренда килешүе төзүгә хокукны сату буенча аукционда катнашырга гаризаларны кире алу турында язма хәбәр кергәннән соң 3(өч) эш көне эчендә;

- аукционда катнашкан, ләкин җиңмәгән затларга - җир кишәрлеген үзмилеккә сату яки аренда килешүе төзүгә хокукны сату буенча аукцион нәтиҗәләре имзаланганнан соң 3(өч) эш көне эчендә.

## IV. Административ регламентның үтәлешен тикшереп тору формалары.

4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча Административ регламентның үтәлешен агымдагы тикшереп тору МБ идарәсе тарафыннан башкарыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең бөтенлеге һәм сыйфаты буенча агымдагы тикшереп тору тикшерүләр үткәрүне, гариза бирүченең хокуклары бозылу очракларын ачыклау һәм бетерүне, гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләрен карау, аларга җаваплар әзерләү, карарлар кабул итү, җаваплы хезмәткәрләр һәм вәкаләтле затларның гамәл(гамәл кылмавы)на шикаятьләрен карауны үз эченә ала.

4.2. Тикшерүләр уздыру планлы характерда(яртыеллык һәм еллык эш планы нигезендә башкарыла), тематик характерда(муниципаль хезмәт күрсәтүнең аерым хокуклары һәм килешү төрләре буенча, аерым категория гариза бирүчеләр буенча) һәм планнан тыш характерда (гариза бирүченең төгәл мөрәҗәгате буенча) була.

4.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүгә җаваплы затлар муниципаль хезмәт күрсәтүнең тәртибе һәм сроклары үтәлеше өчен шәхсән җавап бирәләр.

Муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәтне тиешле таләпләргә туры китереп башкаруы өчен җаваплылык, закончалык таләпләренә туры китереп, аларның вазыйфаи күрсәтмәләрендә беркетелә.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылган очракта, гамәлдәге закончалык нигезендә, гаепле затлар җаваплылыкка тартыла.

4.4. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә, муниципаль хезмәт күрсәтүгә җаваплы хезмәткәр тарафыннан 27.07.2006 елгы “Шәхси мәгълүматлар турында” №153-ФЗ таләпләренә туры китереп, шәхси мәгълүматларны эшкәрткәндә аларның куркынычсызлыгы тәэмин ителә.

## V. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, шулай ук вазыйфаи затның яки муниципаль хезмәткәрнең гамәлен(гамәл кылмавын) һәм карарларын судка кадәр(судсыз) шикаять итү тәртибе.

5.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтүнең тәртибе бозылу очракларында, шул исәптән түбәндәге очракларда, шикаять бирергә хокуклы:
- гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтүгә соравын теркәү срогы бозылу;
- муниципаль хезмәт күрсәтүнең срогы бозылу;
- гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен РФ норматив хокукый актлары, РФ субъекты норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән исәпкә алынмаган документларны таләп итү;
- гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен РФ норматив хокукый актлары, РФ субъекты норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән исәпкә алынган документларны кабул итүдән баш тарту;
- гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен РФ норматив хокукый актлары, РФ субъекты норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән исәпкә алынмаган түләү таләп итү;
- муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, вазыйфаи затның муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны, ялгышларны төзәтүдән баш тарту яки әлеге хаталарны төзәтү срогы бозылу;
- муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу РФ норматив хокукый актлары, РФ субъекты норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән нигезләнмәгән очракта муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту.

5.2. Шикаять язма формада кәгазьдә яки электрон формада Курсабаш авыл җирлеге башлыгына башкаручының гамәленә(гамәл кылмавына), карарларына карата бирелә.

Шикаять почта аша, Интернет челтәрен кулланып, МБ идарәсенең рәсми сайты аша, шулай ук шәхси кабул итү вакытында да бирелә ала.

5.3. Шикаять түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:
- карарлары, гамәле (гамәл кылмавы) шикаять ителүче муниципаль хезмәт күрсәткән органның атамасын, вазыйфаи затның яки муниципаль хезмәткәрнең исем-фамилиясен;
- гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме(булган очракта), яшәү урыны, яисә гариза бирүче юридик затның атамасы, урнашу урыны, телефон номеры, почта адресы, электрон адресы (булган очракта);
- карарлары, гамәле (гамәл кылмавы) шикаять ителүче муниципаль хезмәт күрсәткән орган, вазыйфаи зат, яки муниципаль хезмәткәр турында мәълүматны;
- муниципаль хезмәт күрсәткән орган, вазыйфаи зат, яки муниципаль хезмәткәрнең карары, гамәле (гамәл кылмавы) белән ризасызлыгына дәлилләрне. Гариза бирүче тарафыннан шушы дәлилләрне раслаучы документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре бирелә ала.

5.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органга кергән шикаять, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан, шикаять теркәлгәннән соң 15(унбиш) эш көнендә, күрсәтелгән хаталарны, ялгышларны төзәтүдән баш тарткан органны, вазыйфаи затны шикаять иткән очракта яисә әлеге төзәтүләрнең срогы бозылган очракта, шикаять теркәлгәннән соң 5 (биш) эш көнендә каралырга тиеш.

5.5. Шикаятьләрне карау нәтиҗәләре буенча МБ идарәсе түбәндәге карарларның берсен кабул итә:
- шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан кабул ителгән карарны, төзәтүләрне, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе

булып торучы документлардагы басма хаталарны, ялгышларны гамәлдән чыгара, РФ норматив хокукый актлары, РФ субъекты норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән исәпкә алынмаган түләүләрне гариза бирүчегә кире кайтара, һәм шулай ук башка формаларда;

- шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре турында, 5.5 пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгәннән соң икенче көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язма формада яисә аның теләген исәпкә алып электрон формада дәлилле җавап җибәрелә.

5.7. Шикаятьне карау барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга җаваплы вазыйфаи зат, булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.